**СОВЕТ КУЗЕМБЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУЖАМЭТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Карар
Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы

№ 1 «28» ноябрь 2023 ел

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 13 маендагы №1 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Кодекс» АИС, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы ачыклаган ярашмаучанлыкларны бетерүгә бәйле рәвештә

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗамәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында” 2019 елның 13 маендагы №1 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 бүлекнең 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классны чиннар бирү турындагы күрсәтмә кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш».

1.2. 10 бүлекнең 11 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга.

1.3. 18 статьяның 7 пунктында «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.4. 17 статьяның 5 пунктында «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.5. 33 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктына «яисә «коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе» сүзләрен өстәргә.

1.6. 17 статьяның 7 пунктында «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.7. 19 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) муниципаль хезмәткәрләргә чит ил агенты статусы алу».

1.8. 15 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«11) аларга чит ил агенты статусы алу.».

1.9. 18 бүлекнең 3, 8-10, 12, 13, 14 пунктларында, 29 бүлекнең 2 өлешендәге 3 пунктындагы «Татарстан Республикасы Президенты» исемен «Татарстан Республикасы башлыгы» дип үзгәртергә.

2.Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгы: З.Р. Мортазина